**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменения в качественные и количественные показатели критериев, которым должны соответствовать масштабные инвестиционные проекты, для реализации которых допускается предоставление земельных участков в аренду без проведения торгов

В соответствии со статьей $33^3$ Земельного кодекса Республики Татарстан **постановляю**:

1. Внести в качественные и количественные показатели критериев, которым должны соответствовать масштабные инвестиционные проекты, для реализации которых допускается предоставление земельных участков в аренду без проведения торгов, установленные Указом Президента Республики Татарстан от 7 декабря 2015 года № УП-1170 «Об установлении качественных и количественных показателей критериев, которым должны соответствовать масштабные инвестиционные проекты, для реализации которых допускается предоставление земельных участков в аренду без проведения торгов» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 3 ноября 2016 года № УП-981 и от 14 ноября 2016 года № УП-1004), изменение, изложив их в новой редакции согласно приложению к настоящему Указу.

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
09 октября 2019 года
№ УП-611

Приложение
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «09» октября 2019 года

№ УП-611

**Качественные и количественные показатели критериев, которым должны соответствовать масштабные инвестиционные проекты, для реализации которых допускается предоставление земельных участков в аренду без проведения торгов**

| Критерий | Показатель критерия |
|---|---|
| Создание или увеличение количества рабочих мест | Инвестиционный проект предполагает строительство объектов (за исключением строительства индивидуальных жилых домов и (или) многоквартирных домов), размещение которых позволит увеличить количество рабочих мест в муниципальном образовании, на территории которого они располагаются:<br>не менее чем на 50 единиц на территории сельского либо городского поселения или не менее чем на 100 единиц на территории городского округа;<br>не менее чем на 30 единиц на территории опережающего социально-экономического развития «Набережные Челны» при осуществлении ее резидентом видов экономической деятельности, определенных решением Правительства Российской Федерации о создании соответствующей территории опережающего социально-экономического развития (далее также – территория опережающего развития), в том числе на 20 единиц – в течение первого года после включения юридического лица в реестр резидентов территорий опережающего развития, создаваемых на территориях монопрофильных муниципальных образований Российской Федерации (моногородов) (далее – реестр резидентов территорий опережающего развития);<br>не менее чем на 20 единиц на территории опережающего социально-экономического развития «Нижнекамск» или территории опережающего |

| Критерий | Показатель критерия |
|---|---|
| | социально-экономического развития «Зеленодольск» при осуществлении резидентом соответствующей территории опережающего развития видов экономической деятельности, определенных решением Правительства Российской Федерации о ее создании, в том числе на 10 единиц – в течение первого года после включения юридического лица в реестр резидентов территорий опережающего развития;<br>не менее чем на 10 единиц на территории опережающего социально-экономического развития «Чистополь» или территории опережающего социально-экономического развития «Менделеевск» в течение первого года после включения юридического лица в реестр резидентов территорий опережающего развития, при осуществлении резидентом соответствующей территории опережающего развития видов экономической деятельности, определенных решением Правительства Российской Федерации о ее создании.<br>Инвестиционный проект управляющей компании индустриального (промышленного) парка или промышленной площадки (далее – управляющая компания) предполагает создание не менее 50 рабочих мест на территории сельского либо городского поселения или не менее 100 рабочих мест на территории городского округа, на территории которого размещаются соответствующие индустриальный (промышленный) парк или промышленная площадка. При этом количество новых рабочих мест определяется с учетом рабочих мест, создаваемых резидентами индустриального (промышленного) парка или промышленной площадки, участвующими в инвестиционном проекте управляющей компании |
| Требование к предполагаемому объему инвестиций | Инвестиционный проект предполагает объем капитальных вложений не менее 350 миллионов рублей (за исключением строительства индивидуальных жилых домов и (или) многоквартирных домов) или:<br>не менее 50 миллионов рублей на территории опережающего социально-экономического развития |

| Критерий | Показатель критерия |
|---|---|
| | «Набережные Челны» при осуществлении ее резидентом видов экономической деятельности, определенных решением Правительства Российской Федерации о создании соответствующей территории опережающего развития, в том числе не менее 5 миллионов рублей – в течение первого года после включения юридического лица в реестр резидентов территорий опережающего развития;<br>не менее 15 миллионов рублей на территории опережающего социально-экономического развития «Нижнекамск» при осуществлении ее резидентом видов экономической деятельности, определенных решением Правительства Российской Федерации о создании соответствующей территории опережающего развития, в том числе не менее 2,5 миллиона рублей – в течение первого года после включения юридического лица в реестр резидентов территорий опережающего развития;<br>не менее 10 миллионов рублей на территории опережающего социально-экономического развития «Зеленодольск» при осуществлении ее резидентом видов экономической деятельности, определенных решением Правительства Российской Федерации о создании соответствующей территории опережающего развития, в том числе не менее 2,5 миллиона рублей – в течение первого года после включения юридического лица в реестр резидентов территорий опережающего развития;<br>не менее 2,5 миллиона рублей на территории опережающего социально-экономического развития «Чистополь» или территории опережающего социально-экономического развития «Менделеевск» в течение первого года после включения юридического лица в реестр резидентов территорий опережающего развития при осуществлении резидентом соответствующей территории опережающего развития видов экономической деятельности, определенных решением Правительства Российской Федерации о ее создании.<br>Инвестиционный проект управляющей компании предполагает общий объем инвестиций не менее 350 миллионов рублей. При этом общий объем инвестиций определяется с учетом инвестиций, |

| Критерий | Показатель критерия |
|---|---|
| | осуществляемых резидентами индустриального (промышленного) парка или промышленной площадки, участвующими в инвестиционном проекте управляющей компании |
| Увеличение ежегодных поступлений от налогов, взимаемых на территории Республики Татарстан | Инвестиционный проект предполагает строительство объектов (за исключением строительства индивидуальных жилых домов и (или) многоквартирных домов), размещение которых позволит увеличить ежегодные поступления от налогов в консолидированный бюджет Республики Татарстан не менее чем на 25 миллионов рублей |
| Предоставление мер по поддержке пострадавших от действий (бездействия) недобросовестных застройщиков граждан, денежные средства которых привлечены для строительства многоквартирных домов (за исключением случаев предоставления земельного участка в соответствии с подпунктом $3^1$ пункта 2 статьи $39^6$ Земельного кодекса Российской Федерации) (далее – пострадавшие граждане) | Инвестиционный проект предполагает строительство многоквартирного дома (многоквартирных домов) общей площадью жилых помещений не менее 5 тысяч квадратных метров и (или) иных объектов капитального строительства и предоставление одной или нескольких из следующих мер по поддержке пострадавших граждан на территории Республики Татарстан:<br>передача в собственность пострадавших граждан жилых помещений. В случае, когда площадь передаваемых жилых помещений превышает площадь жилых помещений, необходимых для предоставления меры по поддержке пострадавших граждан на территории муниципального образования, на котором осуществляется реализация масштабного инвестиционного проекта, допускается предоставление указанной меры поддержки в отношении пострадавших граждан на территории других муниципальных образований Республики Татарстан;<br>осуществление строительства недостроенного недобросовестным застройщиком многоквартирного дома (многоквартирных домов), для строительства которого были привлечены денежные средства пострадавших граждан;<br>погашение требований третьих лиц, не являющихся участниками строительства, по обязательствам, обеспеченным залогом прав застройщика на земельный участок с находящимися на нем неотделимыми улучшениями, с целью обеспечения возможности передачи пострадавшим гражданам |

| Критерий | Показатель критерия |
|---|---|
| | жилых помещений, машино-мест и нежилых помещений в многоквартирном доме и (или) ином объекте строительства. Указанная мера поддержки не предоставляется в случаях возбуждения производства по делу о несостоятельности (банкротстве), в отношении которого применяются положения Федерального закона от 29 июля 2017 года № 218-ФЗ «О публично-правовой компании по защите прав граждан – участников долевого строительства при несостоятельности (банкротстве) застройщиков и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации».<br>Размер меры (мер) поддержки не может быть ниже рыночной стоимости предоставляемого земельного участка с видом разрешенного использования, предусматривающего реализацию масштабного инвестиционного проекта, но не менее 50 миллионов рублей |
| Поддержка лиц, пострадавших от деятельности кредитных или иных финансовых организаций, зарегистрированных на территории Республики Татарстан | Инвестиционный проект предполагает создание объекта капитального строительства (за исключением строительства индивидуальных жилых домов и (или) многоквартирных домов) с одновременным предоставлением мер по поддержке лиц, пострадавших от деятельности кредитных или иных финансовых организаций, зарегистрированных на территории Республики Татарстан, в виде погашения долга таких кредитных или иных финансовых организаций перед лицами, внесенными в соответствующий реестр организации, созданной Республикой Татарстан для осуществления поддержки указанных лиц, в размере внесенных ими денежных средств.<br>Размер меры поддержки не может быть ниже рыночной стоимости предоставляемого земельного участка с видом разрешенного использования, предусматривающего реализацию масштабного инвестиционного проекта, но не менее 50 миллионов рублей |

_____________

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатуга куймыйча арендага бирү рөхсәт ителгән масштаблы инвестиция проектлары туры килергә тиешле критерийларның сыйфат һәм сан күрсәткечләренә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатуга куймыйча арендага бирү рөхсәт ителгән масштаблы инвестиция проектлары туры килергә тиешле критерийларның сыйфат һәм сан күрсәткечләрен билгеләү турында» 2015 елның 7 декабрендәге ПУ-1170 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 3 ноябрендәге ПУ-981 номерлы һәм 2016 елның 14 ноябрендәге ПУ-1004 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатуга куймыйча арендага бирү рөхсәт ителгән масштаблы инвестиция проектлары туры килергә тиешле критерийларның сыйфат һәм сан күрсәткечләренә, аларны әлеге Указга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 09 октябрь
№ ПУ-611

Татарстан Республикасы
Президентының
2019 елның «09» октябрендәге
ПУ-611 номерлы Указына
кушымта

**Аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатуга куймыйча арендага бирү рөхсәт ителгән масштаблы инвестиция проектлары туры килергә тиешле критерийларның сыйфат һәм сан күрсәткечләре**

| Критерий | Критерий күрсәткече |
|---|---|
| Эш урыннары булдыру яисә аларның санын арттыру | Инвестиция проекты алар урнашкан территориядәге муниципаль берәмлектә эш урыннары санын арттыру мөмкинлеге бирәчәк объектлар төзүне (шәхси торак йортлар һәм (яисә) күпфатирлы йортлар төзүдән тыш) күздә тота:<br>авыл һәм шәһәр җирлекләре территорияләрендә кимендә 50 эш урынына яисә шәһәр округлары территорияләрендә 100 эш урынына;<br>«Чаллы» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә, аның резиденты тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе (алга таба шулай ук – алгарышлы үсеш территориясе) төзү турында карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда кимендә 30 эш урынына, шул исәптән, юридик зат Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләр) территорияләрендә төзелүче алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары реестрына (алга таба – алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары реестры) кертелгәннән соң бер ел дәвамында – 10 эш урынына;<br>«Түбән Кама» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә яисә «Зеленодольск» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә, тиешле алгарышлы үсеш территориясенең резиденты тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аны төзү турында карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда кимендә 20 эш урынына, шул исәптән, юридик зат алгарышлы |

| Критерий | Критерий күрсәткече |
|---|---|
|  | үсеш территорияләре резидентлары реестрына кертелгәннән соң бер ел дәвамында – 10 эш урынына;<br>«Чистай» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә яисә «Менделеевск» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә, тиешле алгарышлы үсеш территориясенең резиденты тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аны төзү турында карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда, юридик зат алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары реестрына кертелгәннән соң бер ел дәвамында – кимендә 10 эш урынына;<br>Индустриаль (сәнәгать) паркы яисә сәнәгать мәйданчыгы идарәче компаниясенең (алга таба – идарәче компания) инвестиция проекты авыл һәм шәһәр җирлекләре территориясендә кимендә 50 эш урыны яисә тиешле индустриаль (сәнәгать) парк яисә сәнәгать мәйданчыгы урнашкан территориядәге шәһәр округы территориясендә 100 эш урыны булдыруны күздә тота. Шул ук вакытта яңа эш урыннары саны идарәче компаниянең инвестиция проектында катнашучы индустриаль (сәнәгать) парк яисә сәнәгать мәйданчыгы резидентлары тарафыннан булдырылачак эш урыннары санын исәпкә алып билгеләнә |
| Инвестицияләрнең фаразланган күләменә таләпләр | Инвестиция проектында гомуми күләме кимендә 350 миллион сумлык инвестиция кертү (шәхси торак йортлар һәм (яисә) күпфатирлы йортлар төзүдән тыш) күздә тотыла яисә:<br>«Чаллы» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә, аның резиденты тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең алгарышлы үсеш территориясе төзү турында карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда кимендә 50 миллион сум, шул исәптән, юридик зат алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары реестрына кертелгәннән соң бер ел дәвамында – кимендә 5 миллион сум күләмендә;<br>«Түбән Кама» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә, аның резиденты |

| Критерий | Критерий күрсәткече |
|---|---|
| | тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең алгарышлы үсеш территориясе төзү турында карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда кимендә 15 миллион сум, шул исәптән, юридик зат алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары реестрына кертелгәннән соң бер ел дәвамында – кимендә 2,5 миллион сум күләмендә;<br>«Зеленодольск» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә, аның резиденты тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең алгарышлы үсеш территориясе төзү турында карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда кимендә 10 миллион сум, шул исәптән, юридик зат алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары реестрына кертелгәннән соң бер ел дәвамында – кимендә 2,5 миллион сум күләмендә;<br>«Чистай» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә яисә «Менделеевск» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә, тиешле алгарышлы үсеш территориясенең резиденты тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аны төзү турында карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда, юридик зат алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары реестрына кертелгәннән соң бер ел дәвамында – кимендә 2,5 миллион сум күләмендә.<br>Идарәче компаниянең инвестиция проектында гомуми күләме кимендә 350 миллион сумлык инвестиция кертү күздә тотыла. Шул ук вакытта инвестицияләрнең гомуми күләме идарәче компаниянең инвестиция проектында катнашучы индустриаль (сәнәгать) парк яисә сәнәгать мәйданчыгы резидентлары тарафыннан кертеләчәк инвестицияләрне исәпкә алып билгеләнә |
| Татарстан Республикасы территориясендә түләтелә торган салымнардан еллык керемнәрнең артуы | Инвестиция проектында Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына еллык салым керемнәрен кимендә 25 миллион сумга арттырырга мөмкинлек бирәчәк объектлар төзү (шәхси торак йортлар һәм (яисә) күпфатирлы йортлар төзүдән тыш) күздә тотыла |

| Критерий | Критерий күрсәткече |
|---|---|
| Акчалары күпфатирлы йортлар төзүгә тотылган, намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) зыян күргән гражданнарга (алга таба – зыян күргән гражданнар) ярдәм күрсәтү буенча чаралар күрү (Россия Федерациясе Җир кодексының 39[6] статьясы 2 пунктының 3[1] пунктчасы нигезендә җир кишәрлекләре бирү очракларыннан кала) | Инвестиция проектында торак бүлмәләрнең гомуми мәйданы кимендә 5 мең квадрат метр булган күпфатирлы йорт (күпфатирлы йортлар) төзү һәм (яисә) Татарстан Республикасы территориясендә зыян күргән гражданнарның хокукларын яклау буенча түбәндәге чараларның берсен күрү күздә тотыла:<br>торак бүлмәләрне зыян күргән гражданнар милкенә тапшыру. Гражданнар милкенә тапшырыла торган торак мәйданы масштаблы инвестиция проекты тормышка ашырыла торган муниципаль берәмлек территориясендәге зыян күргән гражданнарга ярдәм күрсәтү өчен кирәкле торак мәйданыннан артыграк булган очракта, әлеге ярдәм чарасын Татарстан Республикасының башка муниципаль районнары территориясендәге зыян күргән гражданнарга күрсәтергә рөхсәт ителә;<br>зыян күргән гражданнар акчасын файдаланып төзелә торган, намуссыз төзүчеләр төзеп бетермәгән күпфатирлы йортны (күпфатирлы йортлар) төзү;<br>зыян күргән гражданнарга күпфатирлы йортта һәм (яисә) башка төзелеш объектында торак бүлмәләрне, машина кую урыннарын һәм яшәү өчен каралмаган бүлмәләрне тапшыру мөмкинлеген тәэмин итү максатларында төзелештә катнашмаучы өченче затларның торак төзүченең җир кишәрлегенә, аның аерылгысыз өлеше булган яшәү уңайлыкларына хокуклары нигезендә тәэмин ителгән йөкләмәләре буенча таләпләрен канәгатьләндерү. «Бөлгән (банкрот дип игълан ителгән) төзүчеләрдән зыян күргән гражданнарның – өлешле төзелештә катнашучыларның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китереп бөлгенлек (банкротлык) турында эш башланган очракларда әлеге ярдәм чарасы күрсәтелми.<br>Ярдәм чарасы (чаралары) күләме масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыруны күздә тотып, рөхсәт ителгән рәвештә файдалану өчен |

| Критерий | Критерий күрсәткече |
|---|---|
| | бирелгән җир кишәрлегенең базар бәясеннән, шул ук вакытта 50 миллион сумнан да кимрәк булмаска тиеш |
| Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән кредит яисә башка финанс оешмалары эшчәнлегеннән зыян күргән затларга ярдәм күрсәтү | Инвестиция проекты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән кредит яисә башка финанс оешмалары эшчәнлегеннән зыян күргән затларга әлеге кредит һәм финанс оешмаларының Татарстан Республикасы тарафыннан әлеге затларга ярдәм күрсәтүне тормышка ашыру өчен булдырылган тиешле оешмалар реестрына кертелгән затларга алар үзләре керткән акча күләмендә бурычларын кайтару рәвешендә ярдәм күрсәтү чаралары белән беррәттән капиталь төзелеш объекты төзүне (шәхси торак йортлар һәм (яисә) күпфатирлы йортлар төзүдән тыш) күздә тота.<br>Ярдәм күрсәтү чарасының күләме масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыру күздә тотылган, аннан файдалануның рөхсәт ителгән төре булган җир кишәрлегенең базар бәясеннән дә кимрәк, шул ук вакытта 50 миллион сумнан да азрак булырга тиеш түгел |

---